**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

____**03.06.2022**______ г.Казань **№ 106од**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында Нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы Татарстан Республикасы юстиция министрының 2020 елның 26 декабрендәге 157од номерлы боерыгы белән расланган Нигезләмәнең 2.4 пунктының беренче абзацына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2.4. Конкурс комиссиясе составына министр һәм (яки) аның тарафыннан вәкаләт бирелгән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегеннән һәм граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс үткәрелә торган бүлекчәләрдән (кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрелә торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча профессиональ хезмәт эшчәнлеге өлкәсе гамәлгә ашырыла торган бүлекчәләр)), Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук бәйсез экспертлар - тиешле өлкәләрдә һәм граждан хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге төрләрендә кадрлар технологияләре һәм граждан хезмәте мәсьәләләре буенча белгечләр булган, министр таләбе буенча законда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакырылучы фәнни, белем бирү һәм башка оешмалар вәкилләре керә.

Бәйсез экспертның конкурс комиссиясендә булу вакыты өч елдан артмаска тиеш. Күрсәтелгән срокны исәпләү бәйсез эксперт конкурс комиссиясе составына беренче кертелгәннән бирле гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән срокта бәйсез экспертның Министрлыкның аттестация комиссиясендә булу вакыты исәпләнә. Әлеге бәйсез экспертны конкурс комиссиясе составына кабат кертү аның конкурс комиссиясендә булу срогы тәмамланганнан соң өч елдан да алда гамәлгә ашырыла алмый.».

Министр Р.И. Заһидуллин